**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АНДРЕЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**06 апрель 2026 ел** **№ 20**

## Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартндагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлеге Советының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

1.1. «Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 10 мартындагы 180 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 23 маендагы 75 номерлы карары

1.2. «Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 5 ноябрендәге 103 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 20 июнендәге 73 номерлы карары

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга. https://pravo.tatarstan.ru/ һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ һәм җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Андреевка авыл җирлеге Советы Рәисе Н.И. Егорова